МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.11.2019 г.Казань № 1011

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 10 декабрендә 5979 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының халыкка социаль ярдәм өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 14 ноябрендәге 1011 номерлы боерыгы
белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эштән җибәрелеп, эштән җибәрелү вакытында өч яшькә кадәрге бала карау ялында булган һәм эшсезлек буенча пособие алмаучы эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 6 июнендәге 395 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 08.09.2014 № 491, 07.06.2016 № 317, 24.05.2017 № 323, 17.11.2017 №812, 07.05.2018 №350, 18.09.2018 №858, 07.05.2019 №325 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эштән җибәрелеп, эштән җибәрелү вакытында өч яшькә кадәрге бала карау ялында булган һәм эшсезлек буенча пособие алмаучы эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Гариза бирүчеләр: оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эштән җибәрелгән, эштән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге бала карау ялында булган һәм эшсезлек буенча пособие алмаган, эшкә урнашмаган хатын-кызлар (алга таба – гариза бирүче).»;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Үзәк бүлекләрендә гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчада:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5 пунктның алтынчы, җиденче һәм тугызынчы абзацларында «РФ» сүзен «Россия Федерациясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «арифметик хата» сүзләреннән соң «яки шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты).»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эштән җибәрелгән, эштән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге бала карау ялында булган һәм эшсезлек буенча пособие алмаган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык компенсация түләүләрен (алга таба – компенсация) билгеләү | Россия Федерациясе Президентының 1110 номерлы указы; Тәртипнең 11 пунктындагы «г» пунктчасы; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 472 номерлы карарының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | Тәртип |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар | Тәртипнең 11 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән башлап 10 көн эчендә кабул ителә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | Тәртипнең 14 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен | 1. Банк яки башка кредит учреждениесендә ачылган (компенсацияне банк аша алганда) шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, компенсация билгеләү турында гариза. Гаризаның киңәш | Тәртипнең 12, 13 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | ителәә торган рәвеше шушы Регламентка карата 1 нче кушымтада китерелде.<br>2. Бала карау буенча ял бирү турында боерык күчермәсе.<br>3. Бала (балалар) туу турында таныклык күчермәсе – бала (балалар) туу акты Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгән очракларда.<br>4. Хезмәт кенәгәсе.<br>Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.<br>Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гаризаны шулай ук Үзәк бүлегендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә | |

| | | |
|---|---|---|
| | тутырырга мөмкин, аңа гариза бирүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, кул куя.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның 21[1] һәм 21[2] статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);<br>бала (балалар) туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта – балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);<br>эшсезлек буенча пособиенең түләнмәве турында белешмәләр (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләрендә).<br>Аталган документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә | Тәртипнең 13, 13.1 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| органы яисә оешма | барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Гариза бирүче яки аның ышанычлы заты булмаган затның мөрәҗәгать итүе.<br>2. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>3. Документларда төзәтелгән, өстәп язылган, сызылган сүзләр һәм алдан сөйләшенмәгән башка төзәтүләрнең булуы.<br>4. Үзәк бүлегенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләренә | |

| | | |
|---|---|---|
| | туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.<br>5. Әгәр күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында документларның төп нөсхәләре күрсәтелмәү.<br>6. Гариза бирүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:<br>эшсезлек буенча пособие алу;<br>балаларның тулы дәүләт тәэминатында булуы;<br>гариза бирүченең ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүе;<br>тулы булмаган һәм (яисә) ялган (төгәл булмаган) мәгълүматлы гариза һәм (яисә) документлар тапшырылуы | Тәртип |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| алганда чират көтүнең максималь вакыты | | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар килгән көнне.<br>Гариза белән кирәкле барлык документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлегенең ял көненнән яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | 880 номерлы Тәртипнең 2.4 пункты, Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу мөмкинлеге һәм аның сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен гариза бирүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле | 880 номерлы тәртипнең 2.4 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүматны алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтең алу турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплексны мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән дә, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге (шул исәптән тулы | булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен алу өчен зарури гариза белән документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керүенең вакыт озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплексны мөрәҗәгать составында дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| күләмдә) яки файдалана алмау | хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, гариза бирүче тарафыннан Үзәк бүлегенә тапшырылырга мөмкин.<br>Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документлар 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш. | 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты, 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары»; |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.1 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.»;

җиденче абзац көчен югалткан дип танырга;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.2 пунктта:

дүртенче абзацта «әлеге Регламентның 2.8 пункты» сүзләрен «әлеге Регламентның 2.7 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша килгәндә, – гариза һәм докуметлар Үзәк бүлегенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлегенең эш сәгате тәмамланган вакытта алынган очракта, аннан соңгы эш көнендә. Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлегенең ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.»;

3.5 пунктның өченче абзацында «әлеге Регламентның 2.9 пункты» сүзләрен «әлеге Регламентның 2.8 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Техник хаталарны төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлектә:

4.2 пунктның беренче абзацында «(алга таба - Идарә (бүлек))» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Гариза бирүчеләр судка кадәр тәртиптә Үзәк бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Үзәк бүлеге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Үзәк бүлеге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Үзәк җитәкчесенә тапшырыла.

Үзәк җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.»;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләренең составы ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение хезмәткәре булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

1 нче кушымтада:

«(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)» сүзләрен «гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең тулсынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«СНИЛС (алучыныкы)» сүзләрен «СНИЛС (гариза бирүченеке)» сүзләренә алмаштырырга;

«(дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затның тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)» сүзләрен «гариза бирүченең тулсынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«(гариза бирүченең имзасы)» сүзләреннән соң «, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең тулысынча)» сүзләрен өстәргә;

3 нче кушымтада «(алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)» сүзләрен «гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

5 нче кушымтада «(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)» сүзләрен «гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең тулсынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

кушымтаны (белешмәлекне) түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

«Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эштән җибәрелеп, эштән җибәрелү вакытында өч яшькә кадәрге бала карау елында булган һәм эшсезлек буенча пособие алмаучы эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эштән җибәрелеп, эштән җибәрелү вакытында өч яшькә кадәрге бала карау елында булган һәм эшсезлек буенча пособие алмаучы эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| методология бүлеге башлыгы | | |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru». |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында бер яисә ике ата-анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга ай саен түләнә торган стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 июнендәге 407 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 22.06.2017 №410, 07.05.2018 №353, 18.09.2018 №858, 07.05.2019 №325 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында бер яисә ике ата-анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга ай саен түләнә торган стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзенә алмаштырырга;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Үзәк бүлекләрендә гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт

күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчада:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5 пунктта:

бишенче абзацта «РФ Президентының 601 номерлы указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указы» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «арифметик хата» сүзләреннән соң «яки шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты).»;

2 нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм | ТР Министрлар Кабинеты н 542 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында бер яисә ике ата-анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга ай саен түләнә торган стипендия билгеләү (алга таба – ай саен түләнә торган стипендия) | белән расланган нигезләмә-нең 1.1 пункты |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карары белән расланган нигезләмәнең 1.3 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Ай саен түләнә торган стипендия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карары белән расланган нигезләмәнең 6.9 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору | Ай саен түләнә стипендтя билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар теркәлгән көннән соң эш көннәрендә санала торган 10 көнлек чорда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү айлык стипендия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карары белән расланган нигезләмәнең 6.8 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Айлык стипендия билгеләү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде;<br>белем бирү оешмасын тәмамлап чыгу датасын күрсәтеп, югары белем бирүче мәгариф оешмасыннан белем алуныраслый торган белешмә;<br>медик-социаль экспертиза бюросыннан белешмә күчермәсе – инвалид балалар һәм инвалидлар өчен.<br>Белем алу чорында бер яисә ике ата-анасын югалткан затлар өстәмә рәвештә белем алу чорында бер яисә ике ата-анасын югалтуны раслый торган документларның күчермәләрен тапшыралар.<br>Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Гариза бирүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә һәм банкта ачылган шәхси счет реквизитларын тапшыра.<br>Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Документларның күчермәләре, әгәр дә алар нотариус тарафыннан яисә документның төп нөсхәсен бирүче орган (оешма, учреждение) тарафыннан | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карары белән расланган нигезләмәнең 6.5 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | таныкланмаган булсалар, төп нөсхәләре белән тапшырылалар һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныкланалар.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхес таныклаучы документ күчермәсеннән тыш) нотариус тарафыннан яисә документның төп нөсхәсен биргән орган (оешма, учреждение) тарафыннан таныкланган булырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гаризаны шулай ук Үзәк бүлегендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аңа гариза бирүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, кул куя.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм | Ведомствоара хезмәттәшлек итү каналлары аша түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алучы документлар алына:<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>опека (попечительлек) билгеләү турында – ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карары белән |

| | | |
|---|---|---|
| гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар өчен (җирле үзидарә органнарында);<br>баланың һөнәри белем бирү оешмасында белем алуын раслый торган (тәмамлап чыгу датасын күрсәтеп) (һөнәри белем бирүче оешмаларда);<br>Гариза бирүче үз ихтыяры белән Үзәк бүлегенә шушы пунктта күрсәтелгән документларны, мөмкинлеге булган очракта, электрон рәвештә дә тапшырырга хокуклы.<br>Аталган документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә | расланган нигезләмәнең 6.6, 6.7 пунктлары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20 номерлы карары белән расланган тәртипнең 6 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.<br>2. Гариза бирүченең яисә аның законлы вәкиленең яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән, ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкаләтле затның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешма урнашкан урынга карамаган яисә опекунның (попечительнең) яки гариза бирүченең яшәгән урынына карамаган Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүе.<br>3. Документлар белән әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның яисә аның законлы вәкиленең, яисә гариза бирүче тарафыннан ышаныч кәгазе нигезендә эш итәргә вәкаләтле затның мөрәҗәгать итүе | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>баланың, студентның һөнәри белем бирү оешмасыннан яисә югары белем бирүче мәгариф оешмасыннан куылуы;<br>баланың, студентның үлеме | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | | белән расланган нигезләмәнең 6.13, 6.15 пунктлары |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел. | Россия Федерациясе Президентының 601 |

| | | |
|---|---|---|
| тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | номерлы Указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар килгән көнне.<br>Гариза белән кирәкле барлык документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлегенең ял көненнән яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу мөмкинлеге һәм аның сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүматны алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен гариза бирүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карарының 2.4 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтен алу турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән дә, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге (шул исәптән тулы күләмдә) яки файдалана алмау | чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен алу өчен зарури гариза белән документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керүенең вакыт озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 |

| | | |
|---|---|---|
| үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта), һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | электрон саклагычлардан файдаланып, гариза бирүче тарафыннан Үзәк бүлегенә тапшырылырга мөмкин.<br>Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документлар 63-ФЗ номерлы федераль законда һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш. | номерлы карары белән расланган нигезләмәнең 10.1 пункты;<br>63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты; 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары»; |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.1 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.»;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.1 пунктта:

бишенче һәм тугызынчы абзацларда «әлеге Регламентның 2.8 пункты» сүзләрен «әлеге Регламентның 2.7 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша килгәндә, – гариза һәм докуметлар Үзәк бүлегенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлегенең эш сәгате тәмамланган вакытта алынган очракта, аннан соңгы эш көнендә. Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлегенең ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.»;

3.3.3.1 пунктның өченче абзацында «әлеге Регламентның 2.9 пункты» сүзләрен «әлеге Регламентның 2.8 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.5 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасына ярашлы форма буенча гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.»;

өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

4 бүлектә:

4.2 пунктның беренче абзацында «(алга таба - Идарә (бүлек))» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Гариза бирүчеләр судка кадәр тәртиптә Үзәк бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Үзәк бүлеге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Үзәк бүлеге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Үзәк җитәкчесенә тапшырыла.

Үзәк җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.»;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләренең составы ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение хезмәткәре булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

1 нче кушымтада:

«(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)» сүзләрен «гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең тулсынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«СНИЛС (алучыныкы)» сүзләрен «СНИЛС (гариза бирүченеке)» сүзләренә алмаштырырга;

«(дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затның тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)» сүзләрен «гариза бирүченең тулсынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«(гариза бирүченең имзасы)» сүзләреннән соң «, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең тулысынча)» сүзләрен өстәргә;

3 нче кушымтада:

«(алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)» һәм «алучының (гариза бирүченең) фамилиясе, исеме, атасының исеме)» сүзләрен «гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«Алучының адресы» һәм «Алучының (гариза бирүченең) адресы» сүзләрен «Гариза бирүченең адресы» сүзләренә алмаштырырга;

6 нчы кушымтада «(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)» сүзләрен «гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкиленең тулсынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

кушымтаны (белешмәлекне) түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында бер яисә ике ата-анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга ай саен түләнә торган стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы хисабыннан төп һөнәри белем бирү программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында бер яисә ике ата-анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга ай саен түләнә торган стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru». |

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып калган хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү ялын уздыруга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 20 июнендәге 445 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 04.09.2014 №485, 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №399, 08.06.2017 №351, 07.05.2018 №352, 18.09.2018 №885, 07.05.2019 №324 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып калган хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү ялын уздыруга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Гариза бирүче – законлы вәкил (ана, ата, уллыкка алучы, опекун яки попечитель) яки балалар белән бергә яши торган якын туган (дәү әни, дәү әти), түбәндәгеләргә карата:

Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ

төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып калган хәрби хезмәткәрләрнең балалары;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан пенсия түләнә торган, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып калган, контракт буенча хәрби хезмәт узган хәрби хезмәткәрләрнең һәм Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм стихияле бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү буенча министрлыгының эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары хезмәткәрләренең балалары (алга таба – гариза бирүче).

1.3 пунктны көчен югалткан дип таныргa;

1.4 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

1.4.1 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Идарәнең (бүлекнең) урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Идарәләрдә (бүлекләрдә) урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм тестлы мәгълүматларны үз эченә алган, дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчада:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык)» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацны көчен югалткан дип таныргa;

1.5 пунктның бишенче һәм алтынчы абзацларында «РФ» сүзен «Россия Федерациясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «арифметик хата» сүзләреннән соң «яки шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты).»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып калган хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү ялын уздыруга пособие (алга таба – пособие) билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1051 номерлы карарының 1 пункты |
| 2.2. Башкарма хакимият органы исеме | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районы яисә шәһәр округының социаль яклау идарәсе (бүлеге) | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1051 номерлы карары белән расланган кагыйдәләрнең 5 |

| | | |
|---|---|---|
| | | пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар. | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1051 номерлы карары белән расланган кагыйдәләрнең 6 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | Пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар теркәлгән көннән башлап ун көн эчендә кабул ителә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1051 номерлы карары белән расланган кагыйдәләрнең 6 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле | Пособие билгеләү өчен гариза бирүче, ел саен, 1 мартка кадәр, Россия Федерациясе Саклык банкының (филиалында, структур бүлекчәсендә) оешмасында ачылган счет реквизитларын яки яшәгәр урыны буенча адресын күрсәтеп, гариза (гризаның тәкъдим ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән) тапшыра, аңа түбәндәге документлар теркәлә:<br>а) баланың әтисен хәрби хезмәткә чакыруны һәм хәрби хезмәткә | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1051 номерлы карары белән расланган кагыйдәләрнең 4, 4.1, 15 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | чакырылу урыны буенча хәрби комиссариат тарафыннан бирелгән чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүне раслаучы белешмә;<br>б) чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтәгән хәрби хезмәткәрнең һәлак булуын (үлемен, билгеләнгән тәртиптә билгесез югалган дип танылуын, үлгән дип игълан ителүен) раслый торган документның күчермәсе яки дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениесеннән бирелгән, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә хәрби хезмәт узган хәрби хезмәткәргә инвалидлык билгеләнүен раслый торган белешмә.<br>Әлеге Регламентның 1.2 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән балаларга пособие билгеләү турындагы гаризага әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктларында күрсәтелгән документлар урынына хәрби хезмәткәрнең һәлак булуын (үлемен, билгеләнгән тәртиптә хәбәрсез югалган булуын яки үлгән дип игълан ителүен) раслый торган документның күчермәсе яисә дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениесеннән бирелгән, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге | |

| | | |
|---|---|---|
| | территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә хәрби хезмәт узган хәрби хезмәткәргә инвалидлык билгеләнүен раслый торган белешмә теркәлә;<br>в) пособие билгеләнә торган баланың туу турында таныклык күчермәсе, – бала туу (уллыкка алу) турындагы акт Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгән очракларда;<br>г) мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә булган оешмадан баланың төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алуын раслаучы белешмә (мәктәпкәчә белемнең мәгариф программаларыннан тыш).<br>Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.<br>Гариза бирүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының | |

| | | |
|---|---|---|
| | электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге белешмәләрне раслаучы документлар алына:<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);<br>бала (балалар) туу (уллыкка алу) акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта – бала (балалар) тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);<br>балага опека яки попечительлек билгеләнүе турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);<br>пенсия алу фактын раслаучы белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>баланың Татарстан Республикасы | |

| | | |
|---|---|---|
| аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында белешмәләр (гомуми белем бирүче оешмадан);<br>гариза бирүче белән аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда).<br>Гариза бирүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, тапшырырга хокуклы.<br>Аталган документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Идарә (бүлек) гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү | |

| | | |
|---|---|---|
| | кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.<br>3. Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булуы.<br>4. Әгәр күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган | |

| | | |
|---|---|---|
| | булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында документларның төп нөсхәләре күрсәтелмәү.<br>5. Гариза бирүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе.<br>6. Документлар белән әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның яисә аның законлы вәкиленең, яисә гариза бирүче тарафыннан ышаныч кәгазе нигезендә эш итәргә вәкаләтле затның мөрәҗәгать итүе | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:<br>дөрес (төгәл) булмаган мәгълүматларны үз эченә алучы документлар тапшырылу;<br>пособие алу өчен нигез барлыгын дәлилләми торган документлар тапшырылу. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналган хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар килгән көнне.<br>Гариза электрон формада ял көннәрендә яисә эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, теркәүгә алу Идарәнең (бүлекнең) ял көненнән соң яисә эш көне булмаган бәйрәм көненнән соң килүче беренче эш көнендә гамәлгә ашырыла | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны | |

| | | |
|---|---|---|
| көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу мөмкинлеге һәм аның сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:<br>Идарә (бүлек) биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>гариза бирүчеләрдән документлар | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары белән расланган тәртипнең 2.4 пункты;<br>Россия |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүматны алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтен алу турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән дә, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы | кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен гариза бирүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Идарә (бүлек) белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән хезмәттәшлек итүе саны;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен алу өчен зарури гариза белән документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә | Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| күләмдә) мөмкинлеге яки файдалана алмау | гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, гариза бирүче тарафыннан Үзәк бүлегенә тапшырылырга мөмкин.<br>Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш | 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты,<br>210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары»; |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.1 пунктның җиденче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.1 пунктта:

алтынчы абзацта «әлеге Регламентның 2.8 пункты» сүзләрен «әлеге Регламентның 2.7 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша килгәндә, – гариза һәм докуметлар Идарәгә (бүлеккә) килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Идарәнең (бүлекнең) эш сәгате тәмамланган вакытта алынган очракта, аннан соңгы эш көнендә. Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Идарәнең (бүлекнең) ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.»;

3.5.1 пунктның икенче абзацында «әлеге Регламентның 2.9 пункты» сүзләрен «әлеге Регламентның 2.8 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Техник хата төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлектә:

4.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын тикшерүдә тоту Министрлык аппараты бүлегенең әлеге контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле булган һәм Идарәнең (бүлекнең) вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәләре турында нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентларында билгеләнә торган вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«4.2. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Идарә (бүлек) хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм

гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

Регламентның 5.1 пунктының икенче абзацында «министр исеменә» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләренең составы ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение хезмәткәре булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

1 нче кушымтада:

«(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)» сүзләрен «гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең тулсынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«СНИЛС (алучыныкы)» сүзләрен «СНИЛС (гариза бирүченеке)» сүзләренә алмаштырырга;

«(баланың тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)» сүзләрен «баланың тулсынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«(гариза бирүченең имзасы)» сүзләреннән соң «, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең тулысынча)» сүзләрен өстәргә;

4 нче кушымтада:

«(алучының тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)» сүзләрен «(алучының тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта))» сүзләренә алмаштырырга;

«алучының адресы» сүзләрен «Гариза бирүченең адресы» сүзләренә алмаштырырга;

«(баланың тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)» сүзләрен «(баланың тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта))» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 5 нче кушымтада «(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)» сүзләрен «гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең тулсынча фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

кушымтаны (белешмәлекне) түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

«Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып

калган хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү ялын уздыруга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып калган хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү ялын уздыруга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе җитәкчесе | (843) 264-77-29 | pisma@tatar.ru». |